**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 8 июль № 499

г. Казань

«Барс» кышкы спорт төрләре буенча балалар һәм яшүсмерләр өчен республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесен төзү турында

Балалар һәм яшүсмерләр арасында физик культура һәм массакүләм спортны үстерү, кышкы спорт төрләре буенча Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе җыелма командаларына спорт резервын әзерләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының «Барс» кышкы спорт төрләре буенча балалар һәм яшүсмерләр өчен республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – Учреждение) төзү турындагы тәкъдимен, эшчәнлегенең төп максаты Татарстан Республикасында кышкы спорт төрләрен үстерү дип билгеләп кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына:

Учреждениене гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарырга;

ике ай эчендә Учреждение уставын расларга һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив актлары нигезендә башка кирәкле оештыру чараларын тормышка ашырырга;

үзенең норматив хокукый актларын әлеге карарга туры китерергә;

Учреждение уставын раслаганнан соң, ун көн эчендә Казан шәһәре, Тынычлык урамы, 67а йорты адресы буенча урнашкан Учреждениенең эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасының дәүләт милкәте, шул исәптән аеруча кыйммәткә ия күчемле мөлкәт исемлеген Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшырырга;

ел саен, уставы белән күздә тотылган төп эшчәнлек төре нигезендә, Учреждение өчен дәүләт йөкләмәсен расларга.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Учреждение уставын раслаганнан соң, утыз көн эчендә оператив идарә хокукында Учреждениегә эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасының

дәүләт мөлкәтен билгеләнгән тәртиптә беркетергә.

4. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Учреждениенең дәүләт йөкләмәсен үтәү буенча эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының спорт юнәлешендә өстәмә белем бирү өлкәсендәге дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетында каралган ассигнованиеләр чикләрендә тормышка ашырыла;

Учреждениенең дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән берлектә, Учреждение уставын раслаганнан соң алтмыш көн эчендә, физик һәм (яки) юридик затларга дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Учреждение мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны раслау хакында карарлар проектларын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\499.doc